**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» февраль, 2023 ел № 127

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны банк белән озата баруны гамәлгә ашыру очракларын билгеләү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 2 өлеше, «Контрактларны банк белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары (алга таба - 963 номерлы карар) нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны банк белән тәэмин итү «Контрактларны банк белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы раслаган контрактларны банк белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

1.1. контрактның банк тарафыннан контракт түләлеше кысаларында исәп-хисап мониторингын үткәрүдә төзелә торган контрактка карата контрактның башлангыч (максималь) бәясе бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе 50 млн сумнан да ким булмаска тиеш;

1.2. күрсәтелгән контрактны үтәү кысаларында башкарыла торган исәп-хисапларның мониторингын үткәрүгә өстәмә буларак контрактны банк белән тәэмин итүгә карата, кабул ителә торган товарларның, эшләрнең (аларның нәтиҗәләренең), контракт шартларына (киңәйтелгән банк озата баруының) туры килүен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган башка хезмәтләр күрсәтүгә (контрактның башлангыч (максималь) бәясе бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контрактның бәясе 500 млн сумнан да ким булмаса.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Д. Сабитовка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе В.И. Никитин